СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2021 г.Лениногорск № 10

Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19 декабрендә кабул ителгән «Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне һәм Лениногорск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау турында» 98 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 96-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Советының «Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 19 декабрендәге 98 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 статьяның 4.15 пунктында "хезмәт кеңәгәсе" сүзләреннән соң "(булган очракта)" сүзләре белән тулыландырырга;

6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6.5 пунктына өстәргә:

«6.5 Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында,

әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар әлеге вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар.»;

10 статьяда 10.1.3 пунктның 4 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

16 статьяда 16.9 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яки) хезмәт кенәгәсе күчермәсе, шулай ук кирәк булганда, муниципаль хезмәт стажын раслый торган һәм әлеге Кодексның 17 статьясында күрсәтелгән башка документларның күчермәләре;»;

17 статьяда:

17.5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17.5.3 Муниципаль хезмәт стажын раслаучы төп документлар булып билгеләнгән үрнәктәге хезмәт кенәгәсе һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр тора.»;

17.5.3 статьяның 3 абзацында "хезмәт кенәгәсендә" сүзләреннән соң " һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр" сүзләре белән тулыландырырга;

20.1 статьяда 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәт үткән чор өчен хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Н.Г.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов